ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 сентябрь 2024 ел № 5727

Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8504 номерлы Карары белән расланган муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8504 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 16 ноябрендәге 11194 номерлы Карары редакциясендә) расланган муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә милеккә, арендага, даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.8.2.1 пунктына, 8 пунктчаны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«8) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы, аңа карата башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан, җир участогы бирү турында гариза белән шул җир участогында урнашкан бина, корылмалар, алардагы бүлмәләрнең, тәмамланмаган төзелеш объектының милекчесе яки җир участогының хуҗасы мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов